| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

2021 елның 19 апреле Куакбаш авылы №12а

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең
2020 елга бюджеты үтәлеше
турында хисабын раслау хакында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2020 елга бюджеты үтәлеше турында хисабын расларга: керемнәр буенча 13 080 103,46 сум,
чыгымнар буенча 12 169 724,42 сум, керемнәрнең чыгымнардан 910 379,04 сумга артып киткән түбәндәге күрсәткечләр белән:
- «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча 1нче кушымта нигезендә.
- «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре буенча 2нче кушымта нигезендә.

2. «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2020 елга бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 3нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, - җирле үзидарә бинасы, К. Маркс ур., 15, Сходнево-Чертанлы авылында Ирек ур., 5А адресы буенча авыл клубы бинасында, Чүте авылында Тынычлык ур., 8А йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырырга.

«Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова